ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» гыйнвар 2023 ел №07

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»16.12.2022 елның 326 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2023 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында" 01.09.2022 елның 934 номерлы, 14.09.2022 елның 991 номерлы "Дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында" карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 1 өлешендәге 1.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Әгерҗе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында, укучыларга бушлай ике тапкыр кайнар ризык (иртәнге аш, төшке аш) бирү Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән, булган суммадан чыгып:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен туклану бәясе бер көнгә бер кешегә 64,19 сум - республика субсидиясе суммасы;
- озайтылган көн төркеменә йөрүче 1-3 сыйныф укучылары өчен туклану бәясе бер көнгә бер кешегә 26,0 сум - республика субсидиясенең бәясе;

- 5-11 сыйныф укучылары өчен, шәһәр җирлегендә көнгә бер кешегә туклану бәясе 38,0 сум - ата-аналар түләве суммасы, 8,80 сум - республика субсидиясе суммасы;

- 5-11 сыйныф укучылары өчен, авыл җирлегендә көнгә бер кешегә туклану бәясе 21,0 сум - ата-аналар түләве суммасы, 8,80 сум - республика субсидиясе суммасы.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булу көче 01.01.2023 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) вакытлы матбугат басмасында – “Татмедиа” АҖ филиалының “Әгерҗе хәбәрләре” Әгерҗе районы газетасында халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Э.Н. Бонькинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Л.Ф. Нургаянов**